# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 2** **06 декабрь 2021 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче
Карамалы-Елга авылында 2022елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга авылында гражданнар җыены

## КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Туйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (Бер мең) сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 500 (Биш йөз ) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Карамалы-Елга авылында авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (тракторчыга механикалаштырылган кар җыештыру буенча хезмәтләр өчен түләү ,чит оешмаларның юлларны кардан чистарту буенча хезмәтләре өчен түләү );
- Карамалы-Елга авылы урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, лампаларны ,яктырткычларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Карамалы-Елга авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Авыл бәйрәме», нә бүләк, сувенир продукция сатып алу);
- Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру ( эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү) килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Карамалы-Елга авылында күмелгән урыннарны карап тоту (дератизация, тоташ гербицид белән химик эшкәртү, агач кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар алу, контейнер мәйданчыгы урнаштыру, контейнерлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» . мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлил ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы-Елга ур., Сәйдәшев ур., № 19а йорт янында.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Закирова Р.Р.